ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ
ГОРОД НАБЕРЕЖНЫЕ ЧЕЛНЫ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЯР ЧАЛЛЫ ШӘҺӘРЕ
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ**

9 июнь 2017 ел

**КАРАР**

№ 3528

Башкарма комитет резерв фондының
бюджет ассигнованиеләреннән
файдалану тәртибе турында
нигезнамәне раслау хакында

Россия Федерациясе Бюджет кодексының 81 маддәсе нигезендә

К А Р А Р  Б И Р Ә М:

1. Башкарма комитет резерв фондының бюджет ассигнованиеләреннән файдалану тәртибе турында нигезнамәне кушымтада каралганча расларга.

2. Үз көчен югалткан дип танырга:

1) Башкарма комитетның «Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының резерв фонды турында нигезнамәне раслау хакында» 2010 елның 20 июлендәге 4812 нче карары;

2) Башкарма комитетның «Башкарма комитетның 2010 елның 20 июлендәге 4812 нче карары белән расланган Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының резерв фонды турында нигезнамәгә үзгәрешләр кертү хакында» 2011 елның 12 декабрендәге 6793 нче карары.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасары, финанс идарәсе башлыгы Ә.А. Галиәкбәровага йөкләргә.

Башкарма комитет
Җитәкчесе

Р.Ә. Абдуллин

Башкарма комитетның
2017 елның 9 июнендәге
3528 нче карарына
кушымта

Башкарма комитет резерв фондының
бюджет ассигнованиеләреннән файдалану тәртибе турында
нигезнамә

1. Әлеге нигезнамә Россия Федерациясе Бюджет кодексының 81 маддәсе нигезендә әзерләнде һәм Башкарма комитет резерв фондының (алга таба – резерв фонды) бюджет ассигнованиеләреннән файдалану тәртибен билгели.

2. Резерв фонды шәһәр бюджетының чыгым өлешендә формалаштырыла.

3. Резерв фондының күләме Шәһәр Советының шәһәр бюджеты турындагы карары белән билгеләнә һәм Шәһәр Советының күрсәтелгән карары белән расланган чгымнарның гомуми күләменең өч процентыннан артырга тиеш түгел.

4. Резерв фонды акчалары түбәндәгеләргә юллана:

1) бәла-каза һәм башка гадәттән тыш хәлләр нәтиҗәләрен бетерү белән бәйле авария-торгызу эшләре һәм башка чаралар үткәрүгә;

2) бәла-каза һәм гадәттән тыш хәлләр нәтиҗәсендә зыян күргән гражданнарга бер тапкыр бирелә торган матди ярдәм түләүгә;

3) шәһәр бюджетының тиешле бүлеге (бүлекчәсе) буенча каралган акчалар җитәрлек булмаган очракта, шәһәрнең муниципаль учреждениеләре хезмәткәрләренә хезмәт хакы түләүгә;

4) шәһәр бюджетының тиешле бүлеге (бүлекчәсе) буенча каралган акчалар җитәрлек булмаган очракта, ачык норматив йөкләмәләрне үтәүгә.

5. Бер тапкыр бирелә торган матди ярдәм өчен резерв фондыннан акча алу нияте булган физик затлар, әлеге нигезнамә кушымтасында каралган форма буенча, Башкарма комитет Җитәкчесе адресына мөрәҗәгать юллыйлар.

6. Башкарма комитетның вазыйфаи затлары арасында хезмәт вазыйфаларын бүлешү турында Башкарма комитет боерыгы нигезендә, гадәттән тыш хәлләр нәтиҗәләрен кисәтү һәм бетерү мәсьәләсен координацияләүче (контрольдә тотучы, кураторлык итүче) Башкарма комитетның вазыйфаи затлары, физик зат мөрәҗәгате каран тикшерелгәннән яки бәла-каза һәм башка гадәттән тыш хәлләр булганнан соң бер эш көне эчендә, резерв фондыннан акча бүлеп бирү өчен кирәкле акчалар күләмен һәм (яки) бәла-каза, гадәттән тыш хәлләр булу фактын һәм әлеге хәлләр

нәтиҗәсендә физик затларга зыян килү фактын раслаучы түбәндәге документларны финанс идарәсенә юллый:

1) Башкарма комитетның гадәттән тыш хәл кертелү турында карары;

2) гадәттән тыш хәлләрне кисәтү, бетерү һәм янгын куркынычсызлыгын тәэмин итү комиссиясенең беркетмәләре;

3) бер тапкыр бирелә торган матди ярдәм өчен резерв фондыннан акча алу нияте булган физик затның мөрәҗәгате;

4) гадәттән тыш хәлләр нәтиҗәсендә гражданнар мөлкәтенә килгән зыянны билгеләү комиссияләренең беркетмәләре;

5) зыян килгән объектны тикшерү акты;

6) мөлкәтләрен югалту сәбәпле финанс ярдәме күрсәтүгә мохтаж гражданнар исемлеге;

7) кичектергесез авария-торгызу эшләренә смета исәп-хисаплары.

7. Финанс идарәсе, әлеге нигезнамәнең 6 пунктында каралган документларны һәм материалларны алган көннән соң өч эш көне эчендә, әлеге нигезнамәнең 4 пунктының 1, 2 пунктчаларында каралган максатлар өчен резерв фонды акчаларыннан файдалану турында Башкарма комитет карары проектын әзерләүне гамәлгә ашыра.

Әлеге нигезнамәнең 4 пунктының 1, 2 пунктчаларында каралган максатлар өчен резерв фонды акчаларыннан файдалану өчен, җирле үзидарә органнарының үз компетенцияләре кысаларында кабул ителгән муниципаль хокукый актлары нигез булып тора.

8. Резерв фондының бюджет ассигнованиеләреннән файдалану турындагы хисап шәһәр бюджеты үтәлеше турындагы еллык хисапка теркәлә.

Башкарма комитет
Аппараты Җитәкчесе — Г.К. Әхмәтова

Башкарма комитет резерв фондының бюджет ассигнованиеләреннән файдалану тәртибе турында нигезнамәгә кушымта

Башкарма комитет
Җитәкчесе
______________________________

Бәла-каза һәм гадәттән тыш хәл булу сәбәпле, сорыйм Сездән, миңа ____________________________________________ бер тапкыр бирелә
(гражданның исеме, туу датасы, шәхесен таныклаучы документ реквизитлары.

торган матди ярдәм күрсәтүегезне.

Күчерү өчен реквизитлар:

________________________________________________________________

________________________________________________________________

________________________________________________________________

________________________________________________________________.

____________________
(гражданның исеме)

____________________
(имза)

____________________
(дата)